Галим, З. 35 ел мәдәният һәм милли хәзинәләр сагында / З. Галим // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 26 (15 апрель). – Б. 3.

# Илдар Юзеев премиясе ияләре билгеле

**Чаллының 2нче гимназиясендә Татарстан Язучылар берлеге һәм «ТАТМЕДИА» АҖнең «Шәһри Чаллы» филиалы «Мәйдан» журналы редакциясе гамәлгә куйган Илдар Юзеев исемендәге әдәби-иҗтимагый премияләр тапшыру тантанасы үтте.**

Бу мәртәбәле бүләк бер ел эчендә «Мәйдан» журналында басылып чыккан иң яхшы әсәрләрнең авторларына, басманы үстерүгә, аның абруен күтәрүгә зур көч куйган редакция хезмәткәренә һәм озак еллар дәвамында журналны яздыру буенча булышлык күрсәткән һәм милли матбугатка ярдәм иткән шәхесләргә бирелә.

Илдар Юзеев премиясенең быелгы лауреатлары:

1нче премия Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тел галиме, язучы Рәфкать Шириаздан улы Шаһиевка тапшырылды. Ул «Мәйдан» журналының 2025 ел 9нчы санында басылган «Сынау, яки Үлгәннән соң яздым» исемле чәчмә әсәре өчен лаек дип табылды.

2нче премия Россия, Башкортстан һәм Татарстан Язучылар берлекләре әгъзасы, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, шагыйрь, журналист Мөнир Мәхмүт улы Вафинга бирелде. Ул «Мәйдан» журналының 2025 ел 12нче санында басылган «Ябыгыз тәрәзәгезне, тәрәзәгез булса...» шигырьләр циклы өчен лаек дип табылды.

3нче премиягә «Мәйдан» журналының хезмәткәре, сайт мөхәррире Гөлнар Караева лаек булды.

25 ел дәверендә журналга хәерхаһлы булып, «Мәйдан» журналын саклауга, үстерүгә зур өлеш керткән Яр Чаллы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Винер Хәмит улы Харисовка Илдар Юзеев исемендәге медаль һәм диплом тапшырылды.

Озак еллар Татарстан Язучылар берлеге белән нәтиҗәле хезмәттәшлек иткән Наилә Гадел кызы Миначева Татарстан Язучылар берлегенең «Әдәбияттагы хезмәттәшлек өчен» медале белән бүләкләнде.

Исегезгә төшерәбез, әлеге премия «Мәйдан» журналында 2001-2005 елларда баш мөхәррир булып хезмәт куйган, ТР Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе, язучы, шагыйрь Факил Сафин тәкъдиме белән 2005 елда булдырыла. 2020 елда Чаллы язучылар оешмасының 40 еллыгына яңадан торгызыла.